ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел/факс 5-75-19

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ТАТАРСКО-ЯМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел/факс 5-75-19

КАРАР
09.11.2019г

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№1

Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлегенең Татар Ямалы,Буаз-Күл, Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татар Ямалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Татар Ямалы авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Татар Ямалы авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 19 ноябренэ билгеләргә.

1.2.Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Буаз-Күл авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 20 ноябренэ билгеләргә.

1.3.Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Бүләк авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 20 ноябренэ билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татар Ямалы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан кала, 2021 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Күмү урыннарын карап тору;

Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны формалаштыру һәм тигезләү,ком һәм таш салу, грейдер белән тигезләү, кышкы юлларны карау.

Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү һәм су чыганакларын рәсмиләштерү;

Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру;

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Татар Ямалы авылы, Ленин урамы, 14 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татар Ямалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Д.Ф.Валиев